**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Исполнительный комитет Татарско-Шуганского сельского поселения Азнакаевского муниципального района
423327, Республика Татарстан, Азнакаевский муниципальный район, с.Татарский Шуган, ул. Советская, д. 41в Тел. (факс) (85592) 36-1-41
Tshug.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге башкарма комитеты

Совет урамы, 41в, Татар Шуган авылы Азнакай муниципаль районы, 423327,
Тел. (факс) (85592) 36-1-41
Tshug.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» август 2017 ел. № 12

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Татар Шуганы авыл җирлегенең озак сроклы чорга бюджет фаразын әзерләү һәм раслау тәртибен, гамәлдә булу чорын, составына һәм эчтәлегенә таләпләрне раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Татар Шуган авыл җирлеге Уставына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Татар Шуган авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Татар Шуган авыл җирлегенең озак сроклы чорга бюджет фаразын әзерләү һәм раслау тәртибен, гамәлдә булу чорын, составына һәм эчтәлегенә карата таләпләрне расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык: Г.З.Мияссарова